| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2018 Казан ш. № 10-99/кс

«Кайбыч ЖКХ» муниципаль унитар предприятиесе өчен 2019 – 2023 елларга эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы "Кайбыч ЖКХ" муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга тарифларны, календарь бүленештә күрсәтеп, әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы "Кайбыч ЖКХ" муниципаль унитар предприятиесе өчен 2019 – 2023 елларга эчәргә яраклы суга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрларын әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы "Кайбыч ЖКХ" муниципаль унитар предприятиесенә һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару

өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча ачарга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 30 ноябрендәге 10-99/кс
номерлы карарына 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы "Кайбыч ЖКХ" муниципаль унитар предприятиесе өчен 2019 – 2023 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, эчәргә яраклы суга тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ел | Эчәргә яраклы суга билгеләнгән тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Кайбыч муниципаль районы | | |
| 1 | "Кайбыч ЖКХ" муниципаль унитар предприятиесе | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 17,85 |
| | | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 18,38 |
| | | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 18,38 |
| | | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | 18,72 |
| | | 2021 елның 1 гыйнварыннан алып 2021 елның 30 июненә кадәр | 18,72 |
| | | 2021 елның 1 июленнән алып 2021 елның 31 | 19,43 |

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ел | Эчәргә яраклы суга билгеләнгән тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | декабренә кадәр | |
| | | 2022 елның 1 гыйнварыннан алып 2022 елның 30 июненә кадәр | 19,43 |
| | | 2022 елның 1 июленнән алып 2022 елның 31 декабренә кадәр | 19,80 |
| | | 2023 елның 1 гыйнварыннан алып 2023 елның 30 июненә кадәр | 19,80 |
| | | 2023 елның 1 июленнән алып 2023 елның 31 декабренә кадәр | 20,54 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 30 ноябрендәге 10-99/кс номерлы карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы "Кайбыч ЖКХ" муниципаль унитар предприятиесе өчен 2019 – 2023 елларга эчәргә яраклы суга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме, тариф төре | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | "Кайбыч ЖКХ" муниципаль унитар предприятиесе | | | | | | |
| 1.1 | Эчәргә яраклы су | 2019 | 1 968,01 | 1 | - | 0 | 0,56 |
| | | 2020 | 2 014,58 | 1 | - | 0 | 0,56 |
| | | 2021 | 2 074,21 | 1 | - | 0 | 0,56 |
| | | 2022 | 2 074,21 | 1 | - | 0 | 0,56 |
| | | 2023 | 2 074,21 | 1 | - | 0 | 0,56 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге